# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

**1 статья.** «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге № 2486 Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11-12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2(2) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Преамбулада «Татарстан Республикасының җир асты байлыклары» сүзләрен «Татарстан Республикасында җир асты байлыклары» сүзләренә алмаштырырга.

2. 1 статьяда:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы» сүзләрен «дәүләт идарәсенең вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга.

3. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм бүтән норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.».

4. 5 статьяның икенче абзацында «дәүләт» сүзен «республика» сүзенә алмаштырырга.

5. 6 статьяда:

икенче абзацта «дәүләт» сүзен «республика» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрнең конкрет күләмнәрен билгеләү;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә продукцияне бүлешү турындагы килешүләрне төзүдә катнашу;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир асты байлыклары кишәрлекләреннән федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә файдалану хокукына конкурслар һәм аукционнар уздыру тәртибен һәм шартларын билгеләүдә катнашу;»;

жиденче абзацта «дәүләт» сүзен «республика» сүзенә алмаштырырга.

6. 7 статьяда: өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика һәм җирле әһәмияткә ия җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләрен лицензияләү;»;

бишенче абзацны төшереп калдырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомумтаралган файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәртү максатларында җир асты байлыкларыннан һәм җирле әһәмияткә ия җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану, шулай ук җирле әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү тәртибен урнаштыру;»;

тугызынчы абзацны төшереп калдырырга;

ундүртенче абзацны төшереп калдырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар запасларының республика балансларын һәм аларның ятмаларының һәм чагылышларының кадастрларын төзү һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен файдаланылучы җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу;»;

уналтынчы абзацны төшереп калдырырга;

унсигезенче абзацта «дәүләт акчалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар» сүзләренә алмаштырырга.

7. 8 статьяның дүртенче абзацында «җир турындагы» сүзләрен төшереп калдырырга.

8. 9 статьяда:

икенче абзацта «җир турындагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Файдалы казылмаларны гомумтаралганнарга кертү тәртибе**

Файдалы казылмаларны гомумтаралганнарга кертү законнар нигезендә башкарыла.».

10. 11 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыклары, җир асты киңлеген һәм җир астында булган файдалы казылмаларны, энергетика һәм башка ресурсларны кертеп, дәүләт милке була. Җир асты байлыкларын биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү мәсьәләләре Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар нигезендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагында була.».

11. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Татарстан Республикасының файдалы казылмалар ятмаларының (җир асты байлыклары кишәрлекләренең) резерв фонды**

Минераль чималның стратегик һәм дефицит төрләренә карата Татарстан Республикасының икътисадый иминлеген билгеләүче ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төбәк һәм җирле әһәмияткә ия файдалы казылмалар ятмаларының (җир асты байлыклары кишәрлекләренең) бер өлеше Татарстан Республикасының резерв фондына кертелергә мөмкин. Татарстан Республикасының резерв фондына файдалы казылмаларның яңа гына ачылган яисә файдалануга тапшырылмаган ятмалары гына кертелергә мөмкин.

Файдалы казылмалар ятмаларын (җир асты байлыклары кишәрлекләрен) Татарстан Республикасы резерв фондына кертү тәртибе һәм алардан файдалану шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

12. 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар**

Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар һәм юридик затлар, шул исәптән гади ширкатьтә катнашучылар, чит ил гражданнары, әгәр федераль законнарда җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирүгә чикләүләр билгеләнмәгән булса, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар булырга мөмкин.

Әгәр федераль законда җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшчәнлекнең аерым бер төрләре белән шөгыльләнү өчен махсус рөхсәт (лицензия) таләп ителә дип билгеләнсә, җир асты байлыкларыннан файдаланучының эшчәнлекнең тиешле төрен башкаруга рөхсәте (лицензиясе) йә җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшчәнлекнең төрләрен башкару хокукына ия булган махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән шартнамәләре булырга тиеш.

Федераль закон нигезендә теркәлгән һәм рөхсәтләр (лицензияләр) алган юридик затлар гына радиоактив материаллар, агулы һәм башка төрле

245

куркыныч калдыклар чыгару һәм күмү эшләрен алып барганда җир асты байлыкларыннан файдаланучылар булалар.».

13. 14 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацында «чыгару» сүзе алдыннан «разведкалау һәм» сүзләрен өстәргә.

14. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары**

Җир асты байлыклары кишәрлекләре файдалануга билгеле бер чорга яисә чоры чикләнмичә тапшырыла.

Җир асты байлыклары түбәндәгечә билгеле бер чорга файдалану өчен тапшырыла:

5 елга кадәр - җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен;

файдалы казылмалардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итә торган техник-икътисадый нигезләүдән чыгып исәпләнә торган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү чорына – файдалы казылмалар чыгару өчен;

25 елга кадәр - җир асты суларын чыгару өчен;

1 елга кадәр - законнар нигезендә җир асты кишәрлекләреннән аз вакытта файдалану хокукы бирелү нигезендә файдалы казылмалар чыгару өчен.

Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган файдалануга һәм махсус сакланылучы геологик объектлар барлыкка китерү өчен файдалануга җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләнмәгән чорга тапшырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану вакыты җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия биргән көннән исәпләнә башлый.

Җир асты байлыкларыннан файдалану чоры, җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча, әгәр ул җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану чоры лицензиясендә килешенгән шартларны үтәсә һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүне төгәлләү яисә ликвидация гамәлләрен башкару кирәк булса, озайтылырга мөмкин.

Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән продукцияне бүлешү турындагы килешү шартларында файдалану чорын озайту тәртибе күрсәтелгән килешү белән билгеләнә.».

15. 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы барлыкка килү нигезләре**

Файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы федераль закон нигезендә түбәндәге нигезләрдә барлыкка килә:

246

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең законнар нигезендә кабул ителгән карарлары;

радиоактив, агулы һәм башка төрле куркыныч калдыкларны локализацияләүне тәэмин итә торган тирән кинлекләрдә мондый калдыкларны күмү максатлары өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары;

җир асты байлыклары дәүләт фонды идарәсенең федераль органы яисә аның территория органы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының законнар нигезендә кабул ителгән уртак карарлары;

җир асты байлыклары дәүләт фонды идарәсе федераль органының яисә аның территория органының Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы органнары белән килештерелгән, җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү максатларында кабул ителгән карарлары;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты кишәрлекләреннән яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен кулланылучы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алунын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнгән тәртибе;

җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салучы федераль законнарда билгеләнгән нигезләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү;

федераль закон нигезендә төзелгән продукция бүлешү турында үз көченә кергән килешү.».

16. 17 статьяның икенче абзацында, 25 статьяның өченче өлешендә, 91 статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә «әлеге Законда» сүзләрен «законда» сүзенә алмаштырырга.

17. 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдаланучының төп хокуклары**

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләргә хокуклы:

лицензиядә яисә продукция бүлешү турындагы килешүдә билгеләнгән максатка туры килерлек эшкуарлык яисә башка төрле эшчәнлекнең теләсә нинди рәвеше өчен җир асты байлыкларының үзенә тапшырылган кишәрлегеннән файдаланырга;

минераль чималдан һәм үз эшчәнлегенең башка нәтиҗәләреннән лицензия яисә продукция бүлешү турындагы килешү нигезендә файдаланырга;

лицензиядә яисә продукция бүлешү турындагы килешүдә башкасы билгеләнмәгән булса, үзенең тау эшләре калдыкларыннан һәм шуларга бәйле эшкәртү житештерүләреннән файдаланырга;

үзенә тапшырылган тау эшләре кишәрлеге чикләрендә файдалы казылмалар ятмаларының мәйданнарында төзелеш алып баруны чикләргә;

лицензия яисә продукция бүлешү турындагы килешү нигезендә үзенә бирелгән тау эшләре кишәрлеге чикләрендә үз акчалары исәбенә, өстәмә рөхсәтләрсез генә жир асты байлыкларын геологик өйрәнүне уздырырга;

лицензия тапшырганда булганнан сизелерлек аерылып торган хәлләр килеп чыкса, лицензия шартларын яңадан карауны сорап, лицензия бирүче органга мөрәҗәгать итәргә.».

18. 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдаланучының төп бурычлары**

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

законнар таләпләрен, шулай ук жир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне алып бару технологиясе һәм минераль чималны беренчел эшкәрткәндәге технология буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) үтәүне;

тау эшләрен алып баруның техник проектлары, планнары һәм схемалары таләпләрен үтәүне, нормативтан тыш югалтуларны, файдалы казылмаларның чыганакларын ярлыландыруны һәм сайлап алып эшкәртүне булдырмауны;

жир асты байлыкларыннан файдалануның барлык төрләре барышында геологик, маркшейдерлык һәм башка документларны алып баруны һәм аларның сакланышын;

геологик мәгълүматның федераль һәм территория фондларына геологик мәгълүмат тапшыруны;

файдалы казылмаларның разведкаланган, чыгарылучы һәм жир куенында калдырылучы запаслары, алардагы компонентлар, файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган максатларда жир асты байлыкларыннан файдалану турындагы дөрес белешмәләрне геологик мәгълүматның федераль һәм территория фондларына, дәүләт статистика органнарына тапшыруны;

жир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып баруны;

билгеләнгән тәртиптә расланган жир асты байлыкларын, атмосфера һавасын, жирләрне, урманнарны, елга-суларны, шулай ук биналарны һәм корылмаларны жир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең

зарарлы йогынтысыннан саклау шартларын регламентлаучы стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) үтәүне;

жир асты байлыкларыннан файдаланганда бозылган жир кишәрлекләрен һәм башка табигать обьектларын киләчәктә файдаланырлык хәлгә китерүне;

ятмаларны эшкәрткәндә һәм (яисә) башка хуҗалык максатларында файдалану мөмкинлеге булган разведкалау тау эшләнешләренең һәм бораулау скважиналарының сакланышын; файдаланырга тиешле булмаган тау эшләнешләрен һәм бораулау скважиналарын билгеләнгән тәртиптә юкка чыгаруны;

лицензиядә яисә продукция бүлешү турындагы килешүдә билгеләнгән шартларны үтәүне, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне вакытында һәм дөрес кертүне.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга яисә алар тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалануга җәлеп ителүче башка юридик һәм физик затларга эшчәнлекнең тиешле төрен үткәрүгә: геологик рәсемгә төшерүгә, файдалы казылмаларны эзләүләргә, разведкалауга, файдалы казылмалар чыгаруның башка алымнарына, җир асты корылмаларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә, җир асты байлыкларыннан файдалануның башка төрләрен үткәрүгә дәүләт лицензиясе (таныклыгы, дипломы) белән расланган махсус квалификациясе һәм тәҗрибәсе булу таләпләре куела.»

19. 20 статьяда «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

20. 21 статьяда:

беренче өлешендә «әлеге Законда» сүзләрен «федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

икенче өлештә «җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче өлештә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

21. 23 статьяның беренче өлешендә «җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы карары буенча» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

22. 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 статья. **Зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмү, агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләре булганнарын) агызып чыгару**

Зарарлы, агулы матдәләрне һәм житештерү калдыкларын күмү, агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләре булганнарын) агызып чыгару федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

23. 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. **Радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны күмү**

Радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны күмү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

24. 28 статьяда «җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

25. 29 статьяда «үзләре теләгәнчә» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә» сүзләрен өстәргә.

26. 30 статьяның өченче өлешендә «Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «федераль закон» сүзләренә алмаштырырга.

27. 31 статьяда:

статьяның исемендә «туктату» сүзеннән соң «, туктатып тору яисә чикләү» сүзләрен өстәргә;

беренче өлешендә:

икенче абзацында «әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалануны озайтуны сорап гариза бирмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектә бишенче абзац өстәргә:

«законнарда каралган шартларны бозып, лицензияне янадан рәсмиләштергән очракта.»;

икенче өлештә:

беренче абзацта «туктатыла» сүзеннән соң «туктатып торыла яисә чикләнелә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

«лицензия хуҗасының инициативасы буенча;

җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан законнарда каралган хисап бирелмәсә яисә ялган мәгълүмат бирелгән булса.».

28. 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату, туктатып тору яисә чикләү тәртибе**

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату, туктатып тору яисә чикләү тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.».

29. 33 статьяны төшереп калдырырга.

250



30. 34 статьяны төшереп калдырырга.

31. 35 статьяның икенче өлешендә «лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуны тәкъдим иткән орган тәкъдиме буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы» сүзләрен төшереп калдырырга.

32. IV бүлекне төшереп калдырырга.

33. V бүлекне төшереп калдырырга.

34. 60 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалануның түләүле булуы**

Җир асты байлыкларыннан файдалану, законнарда каралган очраклардан гайре, түләүле була.

Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр федераль законнар нигезендә түләнә.».

35. 61-72 статьяларны төшереп калдырырга.

36. 75 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«75 статья. **Геологик эшләрне дәүләт исәбенә алу һәм дәүләт теркәве**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча барлык эшләр, файдалы казылмаларны чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр дәүләт исәбенә алынырга һәм дәүләт теркәве узарга тиеш.

Дәүләт исәбен һәм дәүләт теркәвен алып бару җир асты байлыклары дәүләт фонды идарәсенең федераль органы тарафыннан билгеләнүче тәртиптә бердәй система буенча гамәлгә ашырыла.».

37. 76 статьяны төшереп калдырырга.

38. 78 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«78 статья. **Җир асты байлыклары турындагы геологик мәгълүматка милекчелек**

Җир асты байлыкларының геологик төзелеше, алардагы файдалы казылмалар запаслары һәм аларның ятмалары, аларны эшкәртү шартлары турында, шулай ук җир асты байлыкларының башка сыйфатлары һәм үзенчәлекләре турында мәгълүмат дәүләт милкендә яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучы милкендә була.

Финанслау чыганагына карамастан, эшләр башкару нәтиҗәсендә җир асты байлыклары турында алынган теләсә нинди геологик мәгълүмат билгеләнгән рәвештә геологик мәгълүматның федераль фондына һәм

Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына федераль законнар нигезендә тапшырыла.

Дәүләт акчалары исәбенә алынган геологик мәгълүматны куллану тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

39. 79 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минераль чималга карата кондицияләр законнарда билгеләнүче тәртиптә раслана.».

40. 81 статьяда:

беренче өлешендә «Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фонды» сүзләрен «федераль законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар запасларын дәүләт балансына кую һәм аларны дәүләт балансыннан төшереп калдыру федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

өченче өлешне төшереп калдырырга.

41. 82 статьяны төшереп калдырырга.

42. 83 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәнәга әһәмияте булган ятмаларны ачкан, шулай ук файдалы казылмаларның өстәмә запасларын, шулай ук элеккеге ятмаларда аларны куллануның сәнәга әһәмиятен арттырырлык яңа өлкәләрен тапкан яисә яңа ятманы ачу мөмкинлеген теоретик яктан нигезләгән физик затлар беренче ачучылар булалар. Алар ачышларын җир асты байлыклары дәүләт фонды идарәсенең федераль органында федераль законнар нигезендә теркәтергә хокуклы.»;

икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «федераль законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

43. 84 статьяның алтынчы өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга.

44. 91 статьяда:

җиденче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тау эшләнмәләрен һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны продукция бүлешү турындагы килешү нигезендә консервацияләү һәм ликвидацияләү, мондый килешү белән күләме, барлыкка килү һәм аннан файдалану тәртибе законнар нигезендә билгеләнүче һәм инвестор тарафыннан барлыкка китерелүче ликвидация фонды акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

сигезенче өлешне төшереп калдырырга.

45. 92 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар яткан мәйданнарны төзү, шулай ук алар яткан урыннарда җир асты корылмаларын урнаштыру җир асты байлыклары

дәүләт фонды идарәсенең федераль органы яисә аның территория органнары һәм тау эшләре дәүләт күзәтүе органнары рөхсәте белән башкарыла. Бу очракта файдалы казылмаларны чыгару мөмкинлеге тәэмин ителергә яисә төзелешнең икътисадый максатка ярашлы булуы дәлилләнергә тиеш.».

46. 93 статьяда:

беренче өлештә «файдалы казылмаларның запасларын һәм ятмаларын» сүзләрен «хисаплылык һәм» сүзләренә алмаштырырга;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыкларын өйрәнүне, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан геологик тикшереп тору табигатьне саклау һәм башка контроль органнары белән үзара хезмәттәшлектә дәүләт геологик контроле органнары һәм тау эшләре күзәтүе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

47. 94 статьяны төшереп калдырырга.

48. 95 статьяның унберенче абзацында «дәүләт бюджеты акчалары» сүзләрен «дәүләт акчалары» сүзләренә алмаштырырга.

49. 98 статьяның җиденче өлешендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

50. 100 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«100 статья. **Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү дәүләт хакимияте органнары яисә суд тарафыннан аларның вәкаләтләре нигезендә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

51. ХП бүлекне төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 21 ноябре
№ 1193